# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Текмәле авылында 2021 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**31.10.2020ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Текмәле авыл җирлегендә халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Текмәле авыл җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Җирле әһәмияткә ия булган Текмәле автомобиль юлларын карап тоту: Ишкәй урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм/яки ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).
- Күмү урыннарын карап тоту (материал сатып алу, хуҗалык инвентаре саклау өчен йорт урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Җирлек территорияләрен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре күрсәтү;);
- Текмәле авылы зиратында контейнер мәйданчыклары урнаштыру, контейнер, киртәләр алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру ,нигез салу, коймалар урнаштыру);
- Җирлек территориясеннән каты коммуналь калдыкларны чыгару.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт, Текмәле авылы, Ишкәй урамы, 15 нче йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:// pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина